| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| от 14.12.2018 | № 615-пр |

Казан ш.

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 13 сентябрендәге № 2069-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә б о е р а м::

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 13 сентябрендәге № 2069-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик

затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
14.12.2018 № 615-пр
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 13 сентябрендәге № 2069-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.1 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр»;

1.3.4 пунктта:

беренче абзацны «дәүләт хезмәте турында» дигән сүзләрдән соң «, шулай ук, Министрлыкның урнашкан урыны һәм эш графигы турында» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2 подпунктның өченче абзацында «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Мәгълүмати стендларга Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.»;

1.4 пунктның икенче абзацында «(Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1994, №32, 3301 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру

тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);»;

2 бүлектә:

2.4 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацта «утыз көн эчендә» сүзләрен «унҗиде эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган»;

2.5 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасында «гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе» сүзләреннән соң «шул исәптән, электрон формада,» сүзләрен өстәргә;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә җир кишәрлеген милек итеп яки арендага бирү өчен гариза бирүче мөрәҗәгать (1 нче кушымта) белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1. Гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе, физик яки юридик затның вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә, физик яки юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе.

2. Гариза бирүченең бинага, корылмага яисә бүлмәгә булган хокуклары Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса (алга таба - ЕГРН), аның бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе.

3. Гариза бирүченең соралган җир кишәрлегенә хокуклары ЕГРНда теркәлмәгән булса, аның җир кишәрлегенә булган хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе.

4. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) соралган җир кишәрлегендә урнашкан үзенең хокукы булган бөтен биналар, корылмаларның, кадастр номерлары (шартлы, инвентарь) һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән исемлеге кертелгән белдерүе.

Беркетелгән документлар нотариуста яки документның оригиналын биргән органда (оешма) расланмаган булса, документларның копияләре төп нөсхә белән бергә бирелә һәм аларны Министрлык белгече раслый.

Гариза бирүче гариза бланкын Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итеп ала ала.

Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазьдә килеш түбәндәге ысулларның берсе белән тапшыра (юллый) ала:

шәхсән үзе (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);

почта аша юллап;

Мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып № 7 боерыгы нигезендә электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасында «мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары,» сүзләреннән соң «шул исәптән, электрон формада,» сүзләрен өстәргә;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

1. Соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә.

2. Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар һәм (яки) корылмалар турында) ЕГРНнан өземтә.

3. Күчемсез милек объекты турында (бүлмәнең милек хуҗасы мөрәҗәгать иткән очракта, соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар һәм (яки) корылмалардагы бүлмә турында) ЕГРНнан өземтә.

4. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә

5. Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРИП) өземтә.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарында, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган һәм башка оешмаларда булган документларны. Искәрмә булып №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган

документлар тора.

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. Түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында беренче тапкыр документлар тапшырганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган һәм алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, документларның срогы чыгуы яки мәгълүматның үзгәрүе;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукларга каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклануы. Бу хакта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат аша белдерелә, кыенлык тудырылуы өчен гафу үтенелә.»;

2.13 пунктта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать һәм документлар кергән бер көн эчендә.

Электрон формада ял көне (бәйрәм көнендә) кергән запрос ял көненнән (бәйрәмнән) соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.»;

2.15 пунктта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын:

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләренә түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«инвалидларга башка затлар белән бер дәрәҗәдә хезмәт күрсәтелергә комачаулаган каршылыкларны үтәргә булышу.»;

Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләрендә өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентның бозылуы турында нигезле шикаятьләр булмау;»;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктның җиденче абзацында «техник хаталарны төзәтү» сүзләре алдыннан «дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән» сүзләрен өстәргә;

3.3.2 пунктның беренче абзацында «Эш башкару» сүзләреннән «һәм контрольдә тоту (алга таба – эш башкару) сүзләрен өстәргә»;

3.4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган оешма - юридик зат турында яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүмат бирүне сорап Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ФСХ ТРИ)»;

3.4.1 пунктның бишенче абзацында «дүрт көн эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның бишенче абзацында «көн эчендә» сүзләрен «эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

3.5.3 пунктның икенче абзацында «ике көн эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.5 пунктның икенче абзацында «өч көн эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.6 пунктның икенче абзацында «өч көн эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.8 пунктның икенче абзацында «көн эчендә» сүзләрен «эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

3.5.10 пунктның икенче абзацында «бер көн» сүзен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «бер көн» сүзен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

абзац второй пункта 3.6.4 пунктның икенче абзацында «бер көн» сүзен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

абзац второй пункта 3.8.4 пунктның икенче абзацында «көн эчендә» сүзләрен «эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. «5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Гариза бирүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләрен зарланып судка кадәр Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча министрның карарына, кылган (кылмаган) гамәленә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда, әгәр андый туктату федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән мәгълүматны яки документларны таләп итү. №210-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 4 өлешендә каралган очраклар искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, аның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), гариза бирүче физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәлгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелә дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү максатында Министрлык кылган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, гариза

бирүче дәүләт хезмәте алу өчен кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат китерелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелми дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре ачыклана, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.»;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр**

1) җир кишәрлеге бирү турында җир законнары буенча җир кишәрлеген алыш-бирешсез алырга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гаризаның РФ ҖКның 39.10 статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора;

3) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга бирелгән; әлеге коммерциячел булмаган оешманың әгъзасы яисә, җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта, әлеге коммерциячел булмаган оешма гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге шәхси торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен

клммерциячел булмаган оешмага бирелгән, әлеге коммерциячел булмаган оешманың әгъзасы яисә, җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта, әлеге коммерциячел булмаган оешма гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылмалар (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылмалар) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан очраклар яки җир кишәрлегендә Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.36 статьясында каралган объектлар урнаштырылган, яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар, шулай ук җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән һәм анда урнашкан бинага, корылмага, төзелеп бетмәгән объектка мөнәсәбәтле үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү турында яки билгеләнгән таләпләр һәм күрсәтелгән вакытта аны тәртипкә китерү турында карар кабул ителгән, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясының 11 өлешендә каралган бурычлар үтәлмәве чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләти яки муниципаль милек булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, җир кишәрлегендә урнашуы сервитут, ачык сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылмалар), яки Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.11 статьясына туры китереп урнаштырылган объектлар булуы, яисә җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьне шул бинаның, корылманың, андагы бүлмәнең, төзелеп бетмәгән объектның хокук иясе бирүе чыгарма булып тора;

7) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яки әйләнеше чикләнгән һәм аны бирү җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хокукларда рөхсәт ителми;

8) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти яки муниципаль ихтыяҗларда резервка куелган булып, гариза бирүче җир кишәрлеген милек итеп даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә җир кишәрлеген арендага җир кишәрлеген резервка кую турында карар гамәлдә булганнан озаграк вакытка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә; җир кишәрлеген резервка кую максатыннан бирү чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан; җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән шушы җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән

объектның хосусый милек иясе яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган зат мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган; җир кишәрлеге федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән булып, җир кишәрлеген бирү турында әлеге объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган һәм территориянең планы буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән; җир кишәрлеген арендага алу турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән һәм әлеге объектларны төзү йөкләмәсе булган затның мөрәҗәгать итүе чыгарма булып тора;

12) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.11 статьясының 19 пунктына туры китереп урнаштырылган;

13) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле, җир кишәрлеге Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.11 статьясының 4 пунктындагы 4 подпунктына туры китереп ясалган булуы шарт булып торганда, аны сату буенча аукцион үткәрү турында яки арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.11 статьясының 4 пунктындагы 6 подпунктында каралган гариза кергән һәм вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча аукцион үткәрүдән баш тарту карары кабул ителмәгән;

14) җир кишәрлеген куллану рөхсәте җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатларга туры килми; территорияне планлаштыруның расланган проектына туры китереп линияле объект урнаштыру чыгарма булып тора;

15) соралган җир кишәрлеге тулысы белән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, аңа куелган файдалану чикләүләре җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә соралган җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми;

16) җир кишәрлеген белдерелгән хокукларда бирү рөхсәт ителми;

17) мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген ничек куллану рөхсәт ителүе билгеләнмәгән;

18) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге җирләрнең билгеле категорияләренә кертелмәгән;

19) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге бирү буенча алдан килештерелгән карар кабул ителгән, аны гамәлдә булу вакыты чыкмаган, ә җир кишәрлеген бирү турында әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән булса;

20) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максатлары әлеге җир алынган максатларга туры килми; әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йорт тузган һәм сүтелергә яисә төзекләндерелергә тиеш дип танылу сәбәпле, җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган булу чыгарма булып тора;

21) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" Федераль законга туры китереп анықланырга тиеш булганда»;

22) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасына, территорияләрне ызанлау проектына яки урман кишәрлекләренең проект документацмясенә туры китереп ясалган булса да, аларда күрсәтелгәннән ун проценттан да күбрәккә артып китә.»;

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымтаны (белешмәлек) түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы урынбасары<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru» |